# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
(V чакырылыш)

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

**КАРАРЫ**

«24» декабрь 2025 ел № 24 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының "Ютазы районында сәнәгать паркы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү турында" 24.12.2018 ел, № 47 карарына үзгәреш кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында»гы 25.02.1999 ел, № 39-ФЗ Федераль законы, «Конкуренцияне яклау турында»гы 26.07.2006 елгы 135-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында"гы 25.1.1998 ел, № 1872 Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 1999 елның 7 маендагы 284 санлы карары, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 29.07.2011 ел, № 29 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Ютазы муниципаль районында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, предприятиеләргә һәм оешмаларга ярдәм итү, җитештерүне, сәнәгатьне үстерү, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә эш урыннарын арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Ютазы районында сәнәгать паркы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү турында» 24.12.2018 ел, № 47 карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 1 пунктта " 2023-2024 елларга" сүзләрен "2026 елларга" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт

(Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Законлылык, регламент һәм җирлекләр советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль
районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Р.М. Якупов
2-42-05